**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Урсай авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Урсай авылы № 103 «15» декабрь 2023 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Урсай авыл җирлеге Советының 2011 елның 3 мартындагы 19 номерлы «Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм «Урсай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында»гы карарын үз көчен югалткан дип тану турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Урсай авыл җирлеге Советы **карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Урсай авыл җирлеге Советының 2011 елның 3 мартындагы 19 номерлы «Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм «Урсай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында»гы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә http://aznakaevo.tatar.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Рәис _______________ З.Х. Рахимьянова